| | |
|---|---|
| **ГЛАВА БОЛЬШЕРУСАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ УРСАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 10 ноябрь Олы Урсак авылы № 1

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлегенең Олы Урсак авылында
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге Уставының 22 статьясына туры китереп КАРАР КЫЛА:

1.Олы Урсак төп мәктәбендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең Олы Урсак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2023 елның 22 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.Олы Урсак авылы, Җиһаншин урамы, 74 нче йорт адресы буенча урнашкан Күпфункцияле үзәк бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең Олы Урсак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2023 елның 23 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3.Олы Урсак авылы, Зиһаншин урамы, 55 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең Олы Урсак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2023 елның 25 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча билгеләргә.

4.Олы Урсак  авылы, Фадеев урамы, 1 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең Олы Урсак авылында   үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын 2023 елның 26 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча билгеләргә.

5.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2024 елда Татарстан Республикасы Кайбычмуниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:

авыл җирлеге торак пункты территориясен тоту

- материаллар сатып алып урам яктыртуын ремонтлау;

Ленин урамындагы күперне ремонтлау һәм материаллар сатып алу;

торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материаллар сатып алып суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

янгын сүндерү автомашинасын, җиһазларын, биналарын һәм ДЕПО хезмәткәрен тоту;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Русак авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« ӨЧЕН»　　　　　　　　　　　　　　　　　　«КАРШЫ»

6.Әлеге карарны Олы Урсак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга .http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　Зиннәтуллин Г.А.